КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 5 сентябрь г.Казань № 791

Төбәк әһәмиятендәге «1 нче һәм 2 нче чылбырларның Щелоков – Үзәк 220 киловаттлы һава линиясе» электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында ачык сервитут билгеләү турында

Питрәч, Балык Бистәсе, Алабуга, Мамадыш муниципаль районнары һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә Россия Федерациясе Җир кодексының V$^{7}$ бүлеге, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3$^{6}$ статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының саклау зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартларын билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «1 нче һәм 2 нче чылбырларның Щелоков – Үзәк 220 киловаттлы һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге объектны урнаштыруны күздә тота торган территория планировкасын һәм аны ызанлау проектын раслау турында» 2017 ел, 4 сентябрь, 630 нчы карары нигезендә төбәк әһәмиятендәге «1 нче һәм 2 нче чылбырларның Щелоков – Үзәк 220 киловаттлы һава линиясе» электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең төбәк әһәмиятендәге «1 нче һәм 2 нче чылбырларның Щелоков – Үзәк 220 киловаттлы һава линиясе» электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында кушымта нигезендә 1,2695 гектар гомуми мәйданлы җир кишәрлекләренә карата 49 елга ачык сервитут билгеләү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Бу карарга теркәлгән Төбәк әһәмиятендәге «1 нче һәм 2 нче чылбырларның Щелоков – Үзәк 220 киловаттлы һава линиясе» электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында ачык сервитут чикләрен һәм аларның тасвирламасын расларга.

3. Бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның $3^6$ статьясындагы 4 нче пункты нигезендә билгеләнми.

4. Бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән аларның рөхсәт ителгән файдалану нигезендә мөмкин булмаячак яки шактый авыр булачак файдалану вакыты бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бу карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә законнар белән билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

бу карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны рәсми бастырып чыгару өчен Питрәч, Балык Бистәсе, Алабуга, Мамадыш муниципаль районнарына һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә җибәрүне;

әлеге карарның күчермәләрен «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыятенә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләренең хокук ияләренә җибәрүне.

6. «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыятенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләренең хокук ияләре белән ачык сервитутны гамәлгә ашыру турында килешү төзүне;

федераль дәүләт энергетика күзәтчелеген гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының саклау зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартларын билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары нигезендә бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән объектка карата саклау зонасы чикләрен килештерү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итәргә;

бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән электр челтәре хуҗалыгы объектына техник хезмәт күрсәтү буенча тәэмин ителеше өчен ачык сервитут билгеләнгән план (регламент) эшләрен елга бер тапкыр гамәлгә ашыруны.

7. «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыятенә кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләрен аларның рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә, ачык сервитут нигезендә урнаштырылган инженерлык корылмасын, тәэмин ителеше өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек

тәмамланганнан соң, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{50}$ статьясында билгеләнгән вакытларда сүтергә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин